ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ ҺӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

---

# БОЕРЫК

**13.07.2015** **№12-07/43**

**Казан ш.**

Гражданнар мөрәҗәгатьләренә
анализ ясау тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12.05.2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Хокук бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе урынбасары Ф.Г.Хамматовка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь
инспекциясенең “13” июль 2015 ел №12-07/43
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә алынган гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауның бу Тәртибе (алга таба – Тәртип, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12.05.2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән, һәм ул Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибенә карата төп таләпләрне билгели.

Бу Тәртиптә түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

мөрәҗәгать – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазыйфаи затына гражданиннан язмача, электрон документ рәвешендә алынган тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданинның телдән мөрәҗәгате;

тәкъдим – гражданинның законнар һәм башка норматив-хокукый актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль-икътисадый эшчәнлеген һәм башка эшчәнлек төрләрен яхшырту буенча тәкъдиме;

гариза – гражданинның үзенең конституцион хокукларын һәм ирекләрен яки башка затларның конституцион хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыруга ярдәм итү турында үтенече, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары һәм вазыйфаи затлары эшендәге кимчелекләр турында хәбәре яисә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары һәм вазыйфаи затлары эшчәнлегенә карата тәнкыйте;

шикаять – гражданинның үзенең санга сугылмаган хокукларын, ирекләрен яки башка затларның хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында үтенече;

вазыйфаи зат – хакимият вәкиле функцияләрен даими, вакытлыча яки махсус вәкаләт белән башкаручы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә “Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре” 05.08.2005 ел, № 391 Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе компетенциясенә керүче, гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләргә ясала.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә гомуми анализ, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге тарафыннан ясала.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау елына ике тапкыр: ярты еллыкка һәм бер елга ясала.

4. Анализда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

кабул итеп алынган, башка адресларга яңадан җибәрелгән һәм карап тикшерелгән мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрне кертеп;

мөрәҗәгатьләр структурасы һәм тематикасы;

шәхсән кабул итү үткәрүгә җаваплы затлар тарафыннан шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны;

гражданнары кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый актлар һәм башка актлар (булганда) турында.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органнарының эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлекләре начальниклары тарафыннан ясала һәм агымдагы елның 15 гыйнварына кадәр (үткән елга йомгаклау хисабы) һәм агымдагы елның 15 июленә кадәр (ярты еллык йомгаклар буенча), гражданнар мөрәҗәгатьләренә гомуми анализ ясау өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенә җибәрелә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге начальнигы гражданнар мөрәҗәгатьләренә гомуми анализ әзерли һәм аны агымдагы елның 20 гыйнварына кадәр (үткән ел өчен йомгаклау хисабы) һәм агымдагы елның 20 июленә кадәр (яртыеллык йомгаклары буенча) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә тапшыра.

7. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә гомуми анализ елына ике тапкыр Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуниіация челтәрендәге рәсми порталына (http:// gosalcogol.tatar.ru) урнаштырыла.

8. Бу Тәртипнең таләпләрен үтәмәгән очракта Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең вазыйфаи затлары дисциплинар җаваплылыкка тартыла.